Исполнительный комитет
Тихоновского сельского поселения
Менделеевского муниципального
района Республики Татарстан
423655 Менделеевский район с.Тихоново ул. Шишкина д.3а

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Тихоново авыл жирлеге
башкарма комитеты
423655 Менделеевск районы Тихоново авылы Шишкин урамы 3а

тел./факс 8 (85549) 3-43-62, E-mail: Tihon.Men@tatar.ru

17.04.2026 год № 2

КАРАР

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 25 мартындагы 2 нче номерлы карары үз көчен югалтуын тану турында

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында” 2007 елның 26 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында” 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге Башкарма комитетының «2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерү программасын раслау турында» 2019 елның 25 мартындагы 2 нче номерлы карарын программаның гамәлдә булу срогы тәмамлануга бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны җәмәгать урыннарындагы мәгълүмат стендларында, шул исәптән Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында: http://mendeleevsk.tatarstan.ru “Тихоново авыл җирлеге” бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Тихоново авыл җирлеге башлыгы А.Г. Гәрәева